Банк России

# ОНЛАЙН-АЛДАКЧЫЛАРДАН НИЧЕК САКЛАНЫРГА?

**Сезнең банк исәпләрегездән файдалану өчен алдакчыларга сезнең турыда шәхси мәгълүматлар һәм картагызның реквизитлары кирәк**

## Алдакчылар нинди ысуллар кулланалар?

### Алтын таулар вәгъдә итәләр

Түләүле сорашулар, социаль түләүләр, өстәмә табыш бирә торган инвестиция проектлары. Тиз баюга ышанычлык бирү – алдау билгесе.

### Арзан бәяләргә кызыктыралар

Бик зур ташламалар һәм түбән бәяләр – алдакчыларның эш әмәлләре булырга мөмкин.

### Зур вакыйгалар вакытында спекуляция белән шөгыльләнәләр


Мәсәлән, вакцина эшләү өчен акча җыю турында белдерү ясыйлар, үткәрелмәгән рейслар өчен акча кайтарырга вәгъдә итәләр яки дәүләттән дотация алырга тәкъдим итәләр.

### Яшеренәләр

Киң танылган белдерү сайтларында сатучы һәм сатып алучы сыйфатында чыгыш ясыйлар.

## Интернетта акчаларыгызны хәвеф-хәтәрдән ничек сакларга?

1. Антивирус куегыз һәм аны даими рәвештә яңартыгыз.
2. Интернет түләүләр өчен аерым дебет картасы булдырыгыз һәм түләү алдыннан кирәкле сумманы салыгыз.
3. Һәрвакыт электрон почтаның һәм сайтның адресын тикшерегез – алар сайтларның рәсми адресларыннан бер-ике символ белән генә аерылып торырга мөмкин.
4. Таныш булмаган кешеләрнең сылтамалары буенча күчмәгез – шикле белдерүләрне шунда ук алып ташлагыз.
5. Үзегезнең шәхси (персональ) мәгълүматларыгызны беркемгә дә хәбәр итмәгез.



Кибергигиена кагыйдәләре турында тулырак **fincult.info** да укыгыз

Финанс культурасы